| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.12.2024 г.Казань № 346-5/нпс-2024

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 09.08.2023 ел, №109-3/нпс-2023 карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә кадастр эшләренә чик дәрәҗәдә максималь бәяләр һәм торак фондының техник инвентаризациясенә ставкалар билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 06.12.2024 ел, №30-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 09.08.2023 ел, №109-3/нпс-2023 карары (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 29.09.2023 ел, №319-4/нпс-2023, 27.12.2023 ел, №833-7/нпс-2023 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә кадастр эшләренә чик дәрәҗәдә максималь бәяләр һәм торак фондының техник инвентаризациясенә ставкалар билгеләү тәртибенә кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
06.12.2024 ел, №346-5/нпс-2024
карары белән расланды

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 09.08.2023 ел, №109-3/нпс-2023 карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә кадастр эшләренә чик дәрәҗәдә максималь бәяләр һәм торак фондының техник инвентаризациясенә ставкалар билгеләү тәртибенә кертелә торган үзгәрешләр

3.3 пунктта:

дүртенче-бишенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җайга салына торган оешма, чираттагы җайга салу чорына кадәр, елның 1 сентябренә кадәр ел саен Дәүләт комитетына Бәяләр, Ставкалар билгеләү турында тәкъдим кертә.

Җайга салына торган оешма Бәяләр, Ставкалар билгеләү турында тәкъдим бирмәгән очракта, Дәүләт комитеты Бәяләр, Ставкалар билгеләү турында эшне үз инициативасы белән җайга салына торган оешма тарафыннан әлеге Тәртипнең 3.3 пунктының дүртенче абзацында каралган күрсәтелгән тәкъдимне тапшыру срогы тәмамланган көннән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча ача.»;

3.9 пунктка түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

«Бәяләр, Ставкалар билгеләү турындагы эш Дәүләт комитеты инициативасы буенча ачылган очракта, Бәяләр, Ставкалар билгеләү турында эш ачу турындагы карар җайга салына торган оешмага җибәрелми.»;

3.11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.11. Бәяләр, Ставкалар Дәүләт комитеты тарафыннан чираттагы ел башына кадәр, әмма җайга салуның чираттагы чорына кадәрге елның 1 ноябреннән дә соңга калмыйча (Бәяләр, Ставкалар 20 декабрьдән дә соңга калмыйча билгеләнә торган 2024 елдан тыш), әлеге Тәртип нигезендә билгеләнә.»;

3.12 пунктының 2) пунктчасында «җайга салу чорына» сүзләреннән соң «(алга таба – ИПЦ)» сүзләрен өстәргә;

5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Ставкаларны исәпләү мәйданнарга бүленгән бер төр торак корылмалары объектлары төрләре буенча фиксацияләнгән Ставкалар исемлегеннән гыйбарәт.»;

6.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.2. Элек билгеләнгән озак сроклы Бәяләргә, Ставкаларга төп чордан соң килүче елга төзәтмәләр кертү җайга салына торган оешма тарафыннан әлеге Тәртипнең 3.3 пунктында каралган срокларда бирелгән Бәяләргә, Ставкаларга төзәтмәләр кертү турындагы тәкъдим нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);
3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);
4 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы
территориясендә кадастр эшләренә
максималь дәрәҗәдә чик бәяләр һәм
техник инвентаризациягә түләү
ставкалары билгеләү тәртибенә
2 нче кушымта

Бәяләрне, Ставкаларны билгеләү өчен тәкъдим ителә торган
документлар исемлеге

1. Җайга салынулы оешма җитәкчесе кул куйган Бәяләрне, Ставкаларны билгеләү турында тәкъдим.

2. Бәяләрне, ставкаларны билгеләү (үзгәртү) кирәклеген дәлилләүче кыскача аңлатма язуы.

3. Гамәлгә кую документларының күчермәләре.

4. Җайга салынулы эшчәнлек алып баручы оешманың исәпкә алу сәясәте турындагы боерык һәм счетларның эш планы күчермәсе.

5. Төп чордан алдагы елга һәм соңгы хисап датасына бухгалтерлык хисабы (бухгалтерлык балансы, финанс нәтиҗәләре турында хисап).

6. Төп чорга кадәрге ел өчен һәм соңгы хисап датасына үзкыйммәт калькуляциясенә карата матди, өстәмә, башка чыгымнарны һәм чыгымнарның башка маддәләрен аңлату.

7. Җайга салынулы оешмада гамәлдә булган норматив һәм тармак актлары (тариф килешүе, хезмәт өчен түләү турында нигезләмә, премияләү турында нигезләмә, күмәк килешү, штат расписаниесе, П-4 «Хезмәткәрләр саны, хезмәт хакы һәм хезмәткәрләр хәрәкәте турында мәгълүматлар» һ.б.).

8. Җайга салына торган оешма буенча җайга салуның төп чорына кадәрге һәм соңгы хисап датасына тулаем алганда уртача айлык хезмәт хакы турында белешмәләр.

9. Төп производство персоналы хезмәтенә түләүнең төп чорга кадәрге ел өчен төп чорга һәм җайга салына торган чорга еллык фонды турында белешмәләр.

10. Эшчәнлек төрләре буенча төп чорга кадәрге ел өчен һәм соңгы хисап датасына әйләнеш-сальдо исемлеге (20 «Төп җитештерү» счеты, 26 «Гомуми хуҗалык чыгымнары» счеты).

11. Әлеге Тәртипкә 3 нче, 4 нче кушымталар нигезендә тутырылган таблицалар.

Татарстан Республикасы
территориясендә кадастр эшләренә
максималь дәрәҗәдә чик бәяләр һәм
техник инвентаризациягә түләү
ставкалары билгеләү тәртибенә
3 нче кушымта

## Кадастр эшләре составы һәм ызан планына уртача вакыт чыгымнары

| № | Ызан планына кергән кадастр эшләре | Үлч. бер. | Дәвамчанлыгы | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр торак пункты | | | авыл торак пункты | | | торак пунктлар чикләреннән тыш | | |
| | | | индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык-лар | гараж | бакча | индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалыклар | гараж | бакча | индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалыклар | гараж | бакча |
| 1 | Ызан планын әзерләү һәм эшне эшкә тапшыру турында килешү төзү | мин. | | | | | | | | | |
| 2 | Заказчы белән телефон аша урынга чыгу вакытын килештерү | мин. | | | | | | | | | |
| 3 | Объект урнашкан урынга кадәр хәрәкәт итү | мин. | | | | | | | | | |
| 4 | Геодезия төшерелү, абрис төзелгән участок үлчәүләре | мин. | | | | | | | | | |
| 5 | Кире кайту | мин. | | | | | | | | | |
| 6 | Геодезия үлчәүләрен эшкәртү | мин. | | | | | | | | | |
| 7 | Үткәрелгән кыр эшләренең сыйфатын тикшерү (сыйфат контроле) | мин. | | | | | | | | | |
| 8 | КМБДР өземтәләргә заказ | мин. | | | | | | | | | |
| 9 | Документларны өйрәнү | мин. | | | | | | | | | |
| 10 | Компьютер программасында җир участогының урнашу схемасын һәм сызымнарын | мин. | | | | | | | | | |

| № | Ызан планына кергән кадастр эшләре | Үлч. бер. | Дәвамчанлыгы | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр торак пункты | | | авыл торак пункты | | | торак пунктлар чикләреннән тыш | | |
| | | | индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык-лар | гараж | бакча | индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалыклар | гараж | бакча | индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалыклар | гараж | бакча |
| | формалаштыру | | | | | | | | | | |
| 11 | КМБДР алынган өземтәләрне алу, саклау һәм бастыру | мин. | | | | | | | | | |
| 12 | Янәшәдәге җир кишәрлекләренең хокук ияләренә ММЧда белдерүләр урнаштыру юлы белән чикләрне килештерү процедурасы турында хәбәр итү яки хокук ияләренә почта аша хәбәр җибәрү | мин. | | | | | | | | | |
| 13 | Янәшәдәге җир кишәрлекләренең хокук ияләре белән чикләрне килештерү актын рәсмиләштерү һәм имзалау | мин. | | | | | | | | | |
| 14 | Автоматлаштырылган мәгълүмат системасында ызан планын формалаштыру | мин. | | | | | | | | | |
| 15 | Мәгълүмат системасыннан ызан планын бастырып чыгару | мин. | | | | | | | | | |
| 16 | Ызан планын төзүнең дөреслеген тикшерү (сыйфат контроле) | мин. | | | | | | | | | |
| 17 | Электрон чыганакка ызан планын яздыру | мин. | | | | | | | | | |
| 18 | Документларны кабул итү зонасына тапшыру, заказчыга бирү | мин. | | | | | | | | | |

| № | Ызан планына кергән кадастр эшләре | Үлч. бер. | Дәвамчанлыгы | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр торак пункты | | | авыл торак пункты | | | торак пунктлар чикләреннән тыш | | |
| | | | индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык-лар | гараж | бакча | индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалыклар | гараж | бакча | индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалыклар | гараж | бакча |
| | Барлыгы (хезмәт таләпчәнлеге) | мин. | | | | | | | | | |
| | | сәгать | | | | | | | | | |

Татарстан Республикасы
территориясендә кадастр эшләренә
максималь дәрәҗәдә чик бәяләр һәм
техник инвентаризациягә түләү
ставкалары билгеләү тәртибенә
4 нче кушымта

# Кадастр эшләренең уртача бәясен исәпләү

| Күрсәткеч-ләрнең исеме | шәһәр округында һәм җирлектә | | | авыл җирлегендә | | | торак пунктлар чикләреннән тыш | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалыклар | гараж | бакча | индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалыклар | гараж | бакча | индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалыклар | гараж | бакча |
| Предприятие буенча уртача хезмәт хакы (*ХК исп) | | | | | | | | | |
| Белгечнең эш сәгате (уртача эш хакы/21 көн/8 сәг) (*Сәг.-норма бәясе) | | | | | | | | | |
| Хезмәт өчен түләү чыгымнары (*Эш бәясе) | | | | | | | | | |
| Өстәмә чыгымнар коэффициенты (*Коэф.) | | | | | | | | | |
| Кадастр эшләренең бәясе, өстәмә хак салымыннан башка (Хезмәт таләпчәнлеге *Коэф.) | | | | | | | | | |
| Рентабельлек коэффициенты (*Р) | | | | | | | | | |
| Өстәмә хак салымын исәпкә алган эш бәясе (*Түләү күләме) | | | | | | | | | |